# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**25 октябрь, 2019** **№ 1**

« Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004елның 28 июлендә 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 23 октябрендә булган граҗданнар җыены нәтиҗәсе белән «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буа авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?» соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.»

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 91 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 48, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 48 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буа торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Кыр Буа авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.» - соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков